КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 декабрь г.Казань № 1324

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 декабрь, 1053 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 498 нче; 2016 ел, 8 май, 287 нче; 2016 ел, 18 июнь, 413 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 705 нче, 2019 ел, 8 февраль, 82 нче, 2020 ел, 10 февраль, 84 нче, 2021 08 июнь, 441 нче, 2021 ел, 21 октябрь, 990 нчы, 2022 ел, 19 февраль, 138 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.5.6 пунктча өстәргә:

«3.5.6. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби

хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе гражданнарының гаилә әгъзаларына (ата-аналарына, ирләренә), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге Россия Федерациясе гражданнарының гаилә әгъзаларына (ата-аналарына, ирләренә) өлкән яшьтәге гражданнар һәм I, II төркем инвалидлар арасыннан.»;

5.1 пунктның 5.1.8 пунктчасында «3.5.1 - 3.5.3 пунктларда» сүзләрен «3.5.3 пунктның 3.5.1 - 3.5.3, 3.5.5 һәм 3.5.6 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин